УДК 82.091

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# ТАТАР ӘДӘБИ МИРАСЫН РУС ДӨНЬЯСЫНА ЧЫГАРУЧЫ ОЛУГ ШӘХЕС: С.И. ЛИПКИН

В статье представлена краткая биография советского поэта, прозаика и переводчика С.И. Липкина (1911–2003), внесшего значительный вклад в знакомство русскоязычного читателя с классическим наследием татарской литературы. Особое внимание уделено истории его многолетней работы над переводом дастана «Идегей» – произведения, которое в советский период было запрещено и лишь спустя несколько десятилетий стало доступным широкому читателю. Анализируются творческие и научные принципы С.И. Липкина, определявшие его подход к передаче поэтики восточного эпоса. Отмечается, что за выдающийся вклад в развитие татарской литературы и ее популяризацию С.И. Липкин был удостоен Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая.

**Ключевые слова:** С.И. Липкин, татарская литература, художественный перевод, дастан «Идегей», Г. Тукай, литературные связи

The article offers a concise yet analytically focused overview of the life and work of the prominent Soviet poet, prose writer, and translator S.I. Lipkin (1911–2003), whose contributions were instrumental in making the canon of Tatar literary classics accessible to Russian-speaking readers. Particular emphasis is placed on Lipkin's long-term engagement with the translation of the epic Idegey, a text suppressed during the Soviet period and released to the broader readership only several decades later. The study reconstructs the historical, ideological, and textual circumstances surrounding this translation and highlights S.I. Lipkin's methodological approach, which combines philological precision with a nuanced understanding of Turkic poetic traditions. The article also contextualizes Lipkin's work within Soviet translation practices and mechanisms of cultural mediation. For his significant contribution to the dissemination and scholarly interpretation of Tatar literature, Lipkin was awarded the Ghabdulla Tukay State Prize of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** S.I. Lipkin; Tatar literature; translation studies; Idegey epic; Soviet literary culture; Ghabdulla Tukay State Prize; intercultural mediation

Татар әдәби классикасы үрнәкләрен рус телендә укыган кешеләр өчен «С. Липкин тәрҗемәсе» дигән гыйбарә бик тә таныш. Аеруча Габдулла Тукайның «Шүрәле»се, «Кәҗә белән сарыгы»ннан башлап, Муса Җәлилнең «Маобит дәфтәре», Әхмәт Ерикәйнең лирик әсәрләре, Шәехзадә Бабич шигырьләренең без С. Липкин тарафыннан гаять оста һәм матур итеп русчага тәрҗемә ителгәнлеген беләбез.

XX гасырның күренекле шагыйре, тәрҗемәче һәм әдәби фикер иясе Семён Липкин (1911–2003) – күпмилләтле совет әдәбиятының

формалашуына зур өлеш керткән, Шәрык һәм төрки халыклар поэзиясен тәрҗемә итүдә аерым урын тоткан зур шәхес. Аның иҗади мирасы зур географик һәм мәдәни киңлекне колачлый: ул төрле халыкларның борынгы эпосларын югары сәнгати осталык белән рус теленә күчерә, Урта Азия, Кавказ, Һиндстан кебек регионнарда яшәгән милләтләрнең бай поэтик традицияләренә мөрәҗәгать итеп, аларның образлар дөньясын, ритмик төзелешен һәм милли фикерләү үзенчәлекләрен рус телендә саклап бирә. Тәрҗемәче буларак, ул оригиналь текстның эчке музыкасын, ритмын һәм рухын төгәл җиткерүгә зур әһәмият бирә, шуның бәрабәренә күп кенә эпослар һәм поэтик әсәрләр рус телле укучы өчен яңадан ачыла. С. Липкинның эшчәнлеге милләтләр арасындагы мәдәни диалогны тирәнәйтүгә, Шәрык әдәбиятының кыйммәтен киң катлауларга танытуга зур өлеш кертә.

Тууына 115 ел тулу уңаеннан бу могтәбәр шәхесне хөрмәт белән искә алып, аның тәрҗемәче буларак әдәбиятыбызга керткән кыйммәтле өлешен, татар рухын рус телле укучыга җиткерүдәге осталыгын билгеләп үтү кирәктер. С. Липкинның ару-талуны белмәс каләме ярдәмендә без татар классикасының бай дөньясын киң аудиториягә танытa алдык, аның тәрҗемәләре бүген дә әдәби кыйммәткә ия булып, укучыларга рухи азык бирә. Халык язучысы Рәдиф Гаташ, татар әдәбиятын русчага тәрҗемә итүчеләр турында сүз чыккач, болай ди: «Әмма безнең татар шигъриятен яхшы белүче, тәрҗемәчеләрне табып оештыручы – ул Семён Липкин иде. Тукайны да, “Идегәй”не дә русча яңгыраткан олуг шагыйрь-тәрҗемәче хаклы рәвештә Тукай премиясенә лаек булды. Иҗат йортларында аның белән санаулы очрашулар да бу шагыйрьгә хөрмәт хисен арттырды гына. Гомер буена безнең шигъриятне яратуын әйтеп, язып торды ул. Мәскәүдә Югары әдәби курсларга очрашуга килгәндә дә, бу мәхәббәтен кат-кат әйтә торган иде» [2: 171].

Семён Израиль улы Липкин 1911 елның 6 сентябрендә (яңа стиль буенча 19 сентябрь) Одессада эшче гаиләсендә туа. Балалык һәм үсмерлек еллары туган шәһәрендә үтә, шунда урта мәктәпне тәмамлый. 1929 елда Мәскәүгә күчеп килгәч, ул үзенең шигырьләрен Осип Мандельштам, Максим Горький кебек танылган әдипләргә күрсәтә һәм югары бәя ала. Шуннан соң тиз арада «Новый мир» кебек абруйлы журналларда аның исеме күренә башлый, тик илдәге коллективлаштыру чорында әсәрләре тыела, һәм ул 25 ел буена үз иҗаты җимешләрен бастыра алмый: беренче китабын бары тик 56 яшендә генә кулына ала. Шулай да яшь шагыйрь әдәбиятка булган мәхәббәтен югалтмый: фарсы телен өйрәнгәннән соң, 1934 елдан Георгий Шенгелиның «тәрҗемә цехы»на кушыла һәм Көнчыгыш телләреннән әдәби тәрҗемә итү эшенә керешә. 1937 елда Мәскәү инженер-икътисад институтын тәмамласа да, тәрҗемәчелек белән мавыгуын дәвам итеп, осталыгын профессиональ дәрәҗәгә күтәрә.

1940–1950 еллар Семён Липкин иҗаты өчен үзенчәлекле күтәрелеш чоры була. Бу дәвердә ул игътибарын төрле халыкларның борынгы эпик мирасын өйрәнүгә юнәлтә, халык авыз иҗатына, мифологиягә, төрле халыкларның рухи-тарихи тәҗрибәсен саклауга әһәмият бирә. Совет фольклористикасында төрки эпосларны җентекләп өйрәнү һәм аларны рус телле укучыга җитди әдәби дәрәҗәдә тәкъдим итү бурычы куелган бу чорда ул әлеге мирасны күпмилләтле совет мәдәниятенең органик бер өлеше итеп күрә, ә эпик әсәрләрне халыкның тарихи хәтерен саклаучы символик код буларак аңлый. Урта Азия республикаларына барып, җирле фольклорчылар, җырчылар, манасчылар белән аралаша, эпосның рухын, ритмик структурасын һәм халык хәтерен саклаган үзенчәлекләрен төгәл тоя башлый. Нәтиҗәдә, калмык эпосы «Джангар»ны, кыргыз эпосы «Манас»ны, казах эпосы «Кобланды батыр»ны, татар халкының «Идегәй» дастанын, кабардин эпосы «Нарты»ны, һинд халкының «Махабхарата»сын тәрҗемә итә. Белгечләр фикеренчә, аның бу тәрҗемәләре эпосның поэтик телен мөмкин кадәр төгәл генә түгел, ә нечкә иҗади төсмерләрен дә саклап җиткерә. Шулай ук бу чорда С. Липкин Ә. Нәвоиның «Ләйлә һәм Мәҗнүн» һәм «Җиде планета» поэмаларын, Фирдәүсинең «Шаһнамә»сен, тагын М. Турсунзадә, Айбәк кебек авторларның әсәрләрен тәрҗемә итә. Ләкин бу тәрҗемәләрнең кайберләрен, аеруча «Манас» кебек милли эпосларны бастырып чыгару эше төрле идеологик сәбәпләр аркасында бик озакка, хәтта берничә дистә елларга сузыла. Алга таба без махсус тукталачак «Идегәй» дастаны тәрҗемәсенең язмышы аеруча аянычлы була.

1960–1970 елларда С. Липкин иҗаты белән дә ил күләмендә таныла, үзенчәлекле шигърияте югары бәяләнә. Көнчыгыш әдәбияты мирасыннан Кәбир, Рүдәки, Җами, Гомәр Хәйям, Хафиз әсәрләре белән беррәттән, замандаш шагыйрьләрдән Зөлфия, Кайсын Кулиев, Лахути, Сөләйман Стальский, Рәсүл Гамзатов, Давид Кугультинов һ. б. бик күп авторның әсәрләрен рус укучыларына таныта. Нәкъ менә шул чорда татар язучыларыннан Муса Җәлил, Әхмәт Ерикәй, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим шигырьләре дә С. Липкин тәрҗемәсендә дөнья күрә.

1979 ел С. Липкинның иҗат юлында аерым бер борылыш ноктасы булып тора: хатыны шагыйрә Инна Лиснянская белән бергә ул демонстратив рәвештә СССР Язучылар берлегеннән чыга. Ул елны, күп кенә ирекле фикер йөрткән язучылар белән бергә, С. Липкин рәсми әдәби идеологиягә буйсынмаган «Метрóполь» альманахын оештыру эшендә катнаша. Әлеге проект совет әдәбиятындагы вазгыятькә каршы үзенә күрә бер протест формасы буларак туа: альманахта партия контроленә буйсынмаган әсәрләрне цензурасыз бастыру планлаштырыла. Оештыручылар арасында Андрей Битов, Василий Аксёнов, Фазил Искәндәр, Белла Ахмадуллина кебек танылган авторлар булуы проектның гади бер эксперимент кына түгел, ә иҗат иреген яклаган принципиаль бер адым икәнлеген күрсәтеп тора. Әдәбиятның табигый

күптөрлелеген саклау, язучыны бюрократик чикләүләрдән азат итү заруриятен һәрвакыт яклаган С. Липкин да альманахка берничә шигырен бирә. Ул «Метрóполь»не әдәби процессның яңарышы, милли һәм шәхси иҗатның ирекле рәвешен киң катлау укучыга җиткерүдә бер мөмкинлек буларак кабул итә. Альманахның машинкада басылган һәм чит илләргә чыгарылган варианты СССР дәүләт идеологиясе органнары тарафыннан «сәяси демарш» дип бәяләнә. Нәтиҗәдә, әдәби даирәдә зур шау-шу куба: Язучылар берлеге «Метрóполь» авторларына каршы репрессия оештыра: кайсылары берлектән куыла, кайсылары «әңгәмәләргә чакырыла», төрле «дисциплинар чаралар»га дучар ителә. Үзенең истәлекләрендә С. Липкин бу турыда болай дип яза: «Мин Язучылар берлегеннән Инна Лиснянская һәм Василий Аксёнов белән бергә чыктым. Үзен-үзе яклый алмаган ике яшь каләмдәшебезне (Виктор Ерофеев һәм Евгений Попов. – *Ә.С.*) Берлектән чыгаруга протест белдереп, без шарт куйдык: “Ике яшь коллегабызны яңадан әгъзалыкка алмаган очракта, рус язучысының намусы һәм абруе безгә Язучылар берлегендә калырга мөмкинлек бирми”, – дидек. Аларны кире алмадылар. Димәк, чыгарга кирәк. Бу карарны кабул итү җиңел булмады. Дуслар да безгә бу адымны ясамаска киңәш итте, чөнки органнар күзлегеннән караганда, Берлектән үз теләгең белән чыгу – сине куып чыгарудан да начаррак иде» [4: 120–121].

С. Липкин фикеренчә, Дәүләт иминлеге комитеты (КГБ) һәм «аның филиалы булган Язучылар берлеге җитәкчелеге» аларның бу адымын аңламый, аңларга да теләми, әмма үз мәнфәгате өчен оста гына куллана: янәсе, бу проект канунсызлыкка протест буларак түгел, ә «кайберәүләрнең», дисседент булып, Америкага яисә Израильгә китүен җиңеләйтер өчен генә оешкан. Моңа дәлил итеп ул берничә вакыйганы китерә, шуларның берсе турыдан-туры татарлар белән бәйле: «Күптән түгел миңа таныш булмаган татар язучысы Альберт Хәсәновтан хат алдым. Баксаң, ул Казандагы язучылар корылтаенда чыгыш ясап, С. Липкин тыелган булу сәбәпле башка кешеләргә ясаткан яңа тәрҗемәләрнең түбән сыйфатын тәнкыйтьләгән һәм минем тәрҗемәләремне кире кайтарырга чакырган. Икенче көнне исә Хәсәновны КГБга чакырткannар да, җайлап кына, шул ук вакытта куркыта төшеп, болай дигәннәр: “Әй, син, сарык баш татар (баранья татарская башка!), Липкинның күптән Америкага киткәнен белмисеңмени?!”» [4: 121].

С. Липкинның хатыныннан да: «Сез чит илгә китмәдегезмени?!» – дип сораучылар шактый була. «Әйе… Без туган җирне ташларга уйламадык, һөҗүмгә күчәргә дә җыенмадык. Әмма тормыш, үзе бар агышы белән, безне һөҗүмгә этәрде. АКШта, Франциядә, Көнбатыш Германиядә, Англиядә безнең китаплар – шигырьләр, проза, истәлекләр басыла башлады; чит ил матбугатында рус һәм чит телләрдә безнең исемнәрне хөрмәт белән искә алдылар. Бу КГБның бик нык ачуын чыгара иде. Бигрәк тә Иннага эләкте...», – дип яза хатирәләрендә Семён әфәнде. Берлектән чыгу белән бергә аларга Литфондның клиникасына

да юл ябыла, сугыш ветеранына каралган ташламалар да бетә, кайбер каләмдәшләре, эзәрлекләүдән куркып, аларны «танымый» башлый, телефоннан төрле янаулар кылә һ. б. «Дуслар миннән гел: “Метрóполь” альманахында катнашуың аркасында олыгайган яшьтә авыр хәлгә калуыңа үкенмисеңме? – дип сорыйлар иде. Мин исә: “Әйе, үкенәм, ник “Метрóполь”дә шигырьләремне бик аз бастырдым икән дип үкенәм”, – дип җавап бирә идем», – дип искә ала язучы [4: 179].

Язучылар берлегеннән чыккач, тулысынча иҗади иреккә ирешүен аңлаган шагыйрьнең шигырьләре 1981 елда АКШта нәшер ителгән «Время и мы» журналында басыла, алар соңрак «Воля» исемле җыентыкка керә. 1983 елда аның «Декада» дип аталган беренче романы, 1984 елда «Кочевой огонь» дигән мәкаләләр җыентыгы, 1986 елда «Картины и голоса» китабы чит илдә дөнья күрә. Үз әсәрләре дә, тәрҗемәләре дә ватанында басылмаган чорда да С. Липкин, сәяси карашын үзгәртмәгән кебек, актив әдәби эшчәнлеген дә үҗәтлек белән дәвам итә. 1980 еллар ахырына таба сәяси атмосфера үзгәрә башлагач, «Метрóполь» тирәсендәге хәлләргә яңадан бәя бирелә һәм С. Липкин 1987 елда кабат Язучылар берлегенә кабул ителә. Бербер артлы әдәби әсәрләре, хатирә, тәрҗемә китаплары нәшер ителә. 1993 елда аңа А.Д. Сахаров исемендәге «Язучы гражданлык батырлыгы өчен» премиясенең бирелүе дә тулысынча нигезле һәм хаклы адым булып тора. Әлеге вакыйгадан бер ел әүвәл, 1992 елда, С. Липкин Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Бу премия аңа «Идегәй» татар халык дастанын һәм татар поэзиясе классикларын оста тәрҗемә итүе өчен бирелә.

«Идегәй» дастанының татарча һәм русча текстларын басмага әзерләү тарихы 1940 елларда ук башланса да, әсәр халыкка ярты гасырдан соң, үзгәртеп кору чорында гына барып ирешә алды. Дастанның фәнни-аналитик төп вариантын басма китап хәлендә күрү, ни кызганыч, моның өчен күп еллар буе көрәшкән кешеләрнең байтагына: Нәкый Исәнбәт, Хәмит Ярми, Хафиз Рәхмәтуллин, Латыйф Җәләй кебек галимнәргә насыйп булмады.

Дастанның катлаулы язмышы аның русчага тәрҗемә ителүе белән дә турыдан-туры бәйле иде. Бер халыкның тарихи мирасын бөтен Союз киңлегенә чыгару яки чыгармау өчен, бу текстның рус телендәге варианты хакимият тарафыннан җентекләп тикшерелергә тиеш иде. Чөнки нәкъ русча текст нигезендә генә аңа «хан-феодаллар эпосы» дигән идеологик ярлык тагу мөмкин булды; әгәр әсәр русчага тәрҗемә ителмәсә, әлеге гаепләү өчен кирәкле «дәлилләрне» дә табып булмас иде. Шуңа күрә «Идегәй»нең басылып чыгуы – ул әдәби мирасны кайтару гына түгел, ә бәлки тарих һәм идеология бәрелешенә нигезләнгән зур бер көрәш-тартышның чишелүе дә иде. Бу көрәшнең никадәр авыр барганлыгына әсәрне русчага тәрҗемә иткән С. Липкин да турыдан-туры шаһит була: «Эзәрлекләүләр һәм кысулар шәхсият белән генә чикләнмәде – гасырлар буе милли рухны саклап

килгән мөселман һәм буддист халыкларының борынгы эпик поэмалары да шушы басымга дучар ителде. Шуларның беренче корбаны татарларның “Идегәй” дастаны булды» [4: 147].

1941 ел ахырында дастанның асыл (сводный) варианты Казанда Тел, әдәбият фәнни-тикшеренү институтында әзерләнеп беткәч, аны русчага тәрҗемәләү эше С. Липкинга тәкъдим ителә, сүзгә-сүз (подстрочный) тәрҗемәсен Нигъмәт Хәким эшләргә алына. Бу вакытта хәрби корреспондент булып фронтта йөргән С. Липкинны кайтарту эшен дә татарлар оештыра булса кирәк. Үзенең истәлекләрендә ул болай дип яза: «...татар җитәкчелеге үтенече белән мин демобилизацияләндем: сугыш башланыр алдыннан тәрҗемә итә башлаган татар халык эпосы “Идегәй”не тәмамлау вазифасы миңа йөкләнгән иде» [4: 146].

1944 елның июнендә Язучыларның Г. Тукай клубында Казан җәмәгатьчелеге дастанның «Мәскәүдән килгән шагыйрь Семён Липкин тарафыннан башкарылган» русчага тәрҗемәсе белән таныша. Ул әлегә тәрҗемә ителгән 4 мең юлны тыңлаучыларга тәкъдим итә. Тәрҗемә югары бәяләнә, сәнгати яктан да, эчтәлекне саклау җәһәтеннән дә уңышлы дип табыла. Шул ук вакытта әсәрне татар һәм рус телләрендә мөмкин кадәр тизрәк бастыру кирәклеге дә әйтелә. Бу турыда «Кызыл Татарстан» газетасының 1944 елның 11 июнь санында язма да басыла. «Идегәй» дастаны турында бер-бер артлы уңай мәкаләләр чыга тора, әмма 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты эпосны кискен тәнкыйтьләгән махсус карар кабул итә. Халык тарафыннан югары бәяләнгән, сәнгати яктан камил әсәргә сәяси үлчәмнәр аша башка төрле бәя бирелә. Шуннан соң вазгыять тамырдан үзгәрә: «Совет әдәбияты» журналында дастанга каршы кискен рухта язылган мәкалә дөнья күрә. Анда Нәкый Исәнбәтнең «Идегәй»нең 500 еллыгына багышланган фундаменталь тикшерүе дә фәнни яктан нигезсез, ялгыш карашларга корылган дип күрсәтелә [бу турыда кара: 5: 93–103]. Дастанның русча варианты конфискацияләнә, С. Липкин «югарыга» – Лубянкага чакыртыла.

Тагын шагыйрьнең үз истәлекләренә мөрәҗәгать итик: ул «Литературная газета»да «Халык эпосы һәм заман» дип исемләнгән зур, ике полоса алып торган бер мәкалә бастыра. Әлеге язмада ул, башка фикерләр белән беррәттән, «Идегәй» турында да мөһим бер нәтиҗә чыгара: эпоста сурәтләнгән изге күңелле, акыллы көтүче образы тарихи шәхес – Аксак Тимергә каршы сугышкан, Мәскәү белән Литвага яулар оештырган Алтын Урда хакименә һич тә туры килми, ди. Нәкъ менә шул мәкаләдән соң Липкинны Үзәк Комитетка чакырып алалар. Аның белән ҮКның агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире Александров әңгәмә алып бара. С. Липкин Александровның тышкы кыяфәтен хәтерләми, ләкин аның ялагай интонациясен, ачык күренеп торган цинизмын (югары дәрәҗәле чиновник өчен бу иң начар сыйфат түгел, дип искәртә тәрҗемәче) һәм иң мөһиме – үзе тикшерергә тиешле әлеге мәсьәләне бөтенләй белмәвен бик ачык хәтерли.

Моннан тыш, С. Липкин бу кешенең подстрочниклар буенча гына эш итүче уртача сәләтле бер тәрҗемәче белән якын мөнәсәбәттә булуын да белә. Липкинның оригиналдан ясаган тәрҗемәләре тыелгач, әлеге хатын-кыз ул тәрҗемә иткән классик поэзия үрнәкләрен кызу темплар белән яңадан «тәрҗемә итә» башлый. Әңгәмә барышында Еголин[1] да катнаша, әмма ул бер сүз дә әйтми. Кабул итү бүлмәсендә шул ук мәсьәлә буенча Казаннан чакырылган Татарстан партия өлкә комитетының пропаганда секретаре Г. Шәфиков үз чиратын көтеп утыра. Александров Липкинга аның мәкаләсен укыганын, аны «мәгънәле» һәм «эшнең асылын яктыртучы» дип кабул итүен әйтә. Ул, Еголин белән бергә, Липкинның «Идегәй» тәрҗемәсен дә карап чыкканнарын, аны «якты һәм көчле әсәр» дип бәяләүләрен дә өсти. Шуннан соң ул төп сорауны бирә:

– Мәкаләгездә телгә алган патриотизмны сез ничек аңлыйсыз? Эпосны иҗат итүчеләр үзләрен кайсы илнең патриоты дип санаганнар?

Липкин аңлатма бирә:

– Ул ил Дәште Кыпчак дип аталган. Рус елъязмаларында – Алтын Урда.

Александров, бераз кырыслана төшеп:

– Димәк, сүз рус халкын изгән кешеләрне патриот дип атау турында бара? Сез бу турыда уйлап карадыгызмы?

Липкин моңа тарихтан мисал белән җавап кайтара:

– Француз коммунистлары – Каршылык хәрәкәтенең иң батыр патриотлары. Әмма Франция үзе шул ук вакытта, Көнбатыш кебек, колонияләрен изүче дәүләт булып тора түгелме?

Александров елмаеп куя:

– Сез тапкыр кеше икән, – ди ул.

Ә чыгар алдыннан болай дип йомгаклый:

– Эшегезне тыныч кына дәвам итегез. Без Сезне хөрмәт итәбез.

С. Липкин бүлмәдән хушлашып чыкканнан соң, секретарь Шәфиковны чакырып кертә, ә Липкинга кабул итү бүлмәсендә көтеп торырга куша. Ун минуттан Шәфиков бүлмәдән канәгать чырай белән балкып чыга. Секретарь – Липкинның пропуск кәгазен имзалаганнан соң, алар Шәфиков белән икесе буфетка төшәләр. Шәфиков Липкинга, куанып, барлык мәсьәләләр хәл ителүен, дастан бастырылачагын сөйли, аңа тәрҗемәсе һәм мәкаләсе өчен рәхмәтен белдерә. Липкин да күңелен борчып торган мәсьәләнең уңышлы хәл ителүеннән үзендә тынычлану, хәтта җиңү хисе тоя.

Икенче көнне исә Липкин яшәгән коммуналкага ҮКтан хәрби киемле курьер килеп, аңа сургуч белән ябылган пакет бирә: анда «Идегәй»нең русча тәрҗемә тексты була. Пакет белән бергә Еголинның яз-

[1] Үз вакытында Ахматова һәм Зощенко өстеннән идеологик һөҗүм оештырган Жданов «революция бишеге» булган Ленинградның әдәби мохитен «сәламәтләндерү» нияте белән нәкъ менә шул Еголинны «Ленинград» журналының мөхәррире итеп билгеләгән була.

масы да куелган: «Кулъязмагызны кире кайтарам. Аннан алган зәвык хисе өчен Сезгә рәхмәт әйтәм». Липкин бу вакыйганы шәхси җиңү һәм иҗади хөррият символы буларак кабул итә. Ике-өч көннән соң «Большевик» журналының яңа саны чыга, анда «Идегәй» дастаның халыкка каршы, хан-феодаль яклы характерда булуы һәм Татарстан партия оешмасындагы начар хәлләр турында ҮК карары басыла. С. Липкин шунда гына эшнең нәрсәдә икәнен аңлап ала: бу карар, Александров һәм Еголин белән очрашудан соң берничә көн эчендә кабул ителеп, журналда басылып чыга алмый: димәк, бу ике җитәкче карар турында алдан ук белгән, хәтта аны үзләре үк әзерләгән булырга мөмкин. Тик аларның үзе белән һәм Казаннан чакыртылган Татар обкомы вәкиле белән нинди максаттан мондый «кәмит» уйнавын аңлый алмый: бу алардан көлүме, әллә император Павелга иярүме (император, берәр сановникка ачуы чыккан чакта, үзенең хатын, гадәттә, шундый сүзләр белән тәмамлый торган булган: «Ә шулай да, без сезгә даими мәрхәмәтле булып калабыз» [3: 144].

«“Идегәй” турындагы карар милли республикаларда да, Мәскәүдә дә, Ленинградта да галимнәрне һәм язучыларны сискәндереп җибәрде. Куркыныч җилләр азәрбайҗаннарның «Китабе дәдам Коркыт», үзбәкләрнең «Алпамыш», кыргызларның «Манас» кебек башка Көнчыгыш эпосларына таба исә башлады. Элек хупланган һәм Бөтенсоюз күләмендә бәйрәм ителгән әсәрләр хәзер шикле, антисовет, димәк, руска каршы булып санала башлады», – дип яза С. Липкин.

1944 елда «Идегәй» дастаны тирәсендә барлыкка килгән сәяси вазгыять С. Липкинның әдәби һәм шәхси халәтендә аеруча тирән эз калдыра. Ул үзенең эпоска багышланган мәкаләсендә «Идегәй» каһарманының тарихи хан образына турыдан-туры бәйле түгеллеген дәлилләргә тырыша, эпик әсәрнең феодаль-династик интерпретациягә кайтып калмаска тиешлеген ассызыклый. Аның фикеренчә, әлеге дастан – татар халкының тарихны үзенчә күрүе, гасырлар буена сакланган әхлакый һәм социаль кыйммәтләрне бирергә тырышуы формасы.

Шул ук вакытта С. Липкинның ҮК вәкилләре белән әңгәмәләрендә аңа карата ялган мөгамәлә, хәтта икейөзлелек хөкем сөрү, тәрҗемәләрен формаль рәвештә мактап, соңыннан кире кагу шул чор совет мәдәнияте сәясәтенең чынбарлыгын ачык күрсәтә. «Идегәй» турындагы карарның алдан әзерләнгән булуы, Г. Шәфиковның Мәскәүгә кирәксезгә чакыртылуы, ике-өч көн эчендә рәсми матбугатта әлеге дастанның «антинародный» дип игълан ителүе – болар барысы да милли эпосларның идеологик инструментка әйләндерелүен күрсәтә. Казан галимнәре С. Липкинның тәрҗемәсен фәнни яктан хуплап һәм саклап калу өчен тырышлык куйсалар да, рәсми басым һәм цензура аларның мөмкинлекләрен чикли. Нәтиҗәдә, дастанның татарчасы – 1988 елда, русча тәрҗемәсе исә 1990 елда гына басылып чыга.

Шунысы әһәмиятле: бу басым С. Липкинның татар әдәбиятына карашын үзгәртми, киресенчә, иҗади ихтыярын тагын да ныгыта. Ул Тукайның «Шүрәле»сен тәрҗемә иткәндә дә, Нәвои, Рүдәки кебек Шәрык классикларының әсәрләре белән эшләгәндә дә, милли мәдәниятләргә ихтирамын алга планга куя. Аның өчен тәрҗемә – милли мираска хезмәт итү, мәдәниятләр арасындагы чикләрне якынайту, халык авазын аның «үз теленнән» ишеттерү омтылышы. Шуңа күрә С. Липкинның татар әдәбияты белән бәйле эшчәнлеге – бер тәрҗемәченең шәхси иҗат юлы гына түгел, ул совет чорында милли эпосларның язмышын, идеология белән әдәбият каршылыгын, мәдәни мирасны бәяләү һәм саклау тирәсендәге бәхәсләрнең асылын да ачып күрсәтә. С. Липкин мисалында без тәрҗемәнең сүзләрне бер телдән икенче телгә күчерү генә түгел, ә оныттырылган һәм тимер пәрдә артында калган халык хәтере өчен көрәш булуын күрә алабыз.

Үз вакытының башка тәрҗемәчеләре тарафыннан да С. Липкин хезмәтләре югары бәяләнә. Мәсәлән, әдәбиятчы галим һәм тәрҗемәче Вил Ганиев аның хакында болай дип яза: «Татар поэзиясенең образлы фикерләвенә тирән үтеп керүе белән С. Липкин тәрҗемәләре башкалардан аерылып тора. Анда югары поэтик культура татар шигъриятенең чишмә башларын һәм Шәрык поэтикасының үзенчәлекләрен яхшы белү белән органик рәвештә кушылып бара. С. Липкинның Г. Тукай шигырьләренә үзе һәм башкалар ясаган тәрҗемәләренә биргән аңлатмалары (Г. Тукай. Избранное. М., Детгиз, 1956) – татар поэзиясенең үсеш юлын, аның күтәрелеш һәм түбән төшү этапларын дөрес аңлавының ачык дәлиле. Әлеге аңлатмаларның шактые фәнни тикшерену дәрәҗәсендә язылган. Чынлыкта исә тәрҗемә кылынган әсәрнең асылын фәнни нигездә аңлау – поэтик осталыкка ия тәрҗемәче өчен иҗади уңышның төп шартларыннан берсе.

Татар поэзиясеннән эшләнгән иң камил тәрҗемәләрендә С. Липкин... совет тәрҗемә мәктәбе казанышы итеп билгеләнгән "иҗади ирек белән фәнни анализ төгәллеге берлеге"н тормышка ашыра алды. Образлар системасын дөрес аңлау һәм аны рус телендә табигый, җанлы шигъри интонация белән бирү С. Липкин тәрҗемәләрен ирекле ияреп язудан һәм үзешчән югарылыкта гына башкарылган эшләрдән аерып тора» [1: 77].

С. Липкинның тәрҗемә эшендәге масштабы да искиткеч: ул Көнчыгыш классикасыннан гына да якынча 180 мең шигъри юл тәрҗемә итә (чагыштыру өчен: «Илиада»да – 15 700, «Одиссея»дә – 12 100 юл). Ярты гасырга сузылган бу титаник хезмәт үзе генә дә шагыйрь С. Липкин исемен совет әдәби мәдәнияте тарихында мәңгеләштерә. Бу кадәр зур милли байлыкны чын шигъри камиллектә рус телендә бирә алуы өчен аны киләчәк буын укучылары да рәхмәт белән искә алачак.

**Әдәбият**

1. *Ганиев В.* Образность как элемент точности // Мастерство перевода. Сб. 3. 1963. М.: Советский писатель, 1964. С. 63–69.
2. *Гаташ Р.* Әдәби-рухи аралашулар // Казан утлары. 2020. № 5. Б. 169–171.
3. *Липкин С.И.* Вторая дорога. Зарисовки и соображения. М.: Олимп, 1995.
4. *Липкин С.И.* «Угль, пылающий огнем»: Воспоминания о Мандельштаме. Стихи, статьи, переписка. М., 2008.
5. *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Сибгатуллина Альфина Тагировна,***
*доктор филологических наук, ведущий научный сотрудник*
*Института востоковедения Российской Академии наук*

*alfina2003@yandex.ru*